*Кушымта.*

Чын дуслыкны еллар, юллар,
Матур җырлар ныгыта.
Чын дуслыкның чылбырлары
Йөрәкләр аша үтә.

*Кушымта.*

Йөрәкләрдән йөрәкләргә
Күпер салсын моң-җырлар.
Чын дуслыкка киртә түгел
Киң Иделләр, Каф таулар.

*Кушымта.*

## ЮЛДА КӨТСЕН ДУСЛАРЫҢ

Фәнир Галимов көе
(Фәнир Галимов репертуарыннан)

Бисмиллалар әйтеп, юл догасын укып,
Чыгып китәм озын юлларга.
Озын юллар — хәтәр, бәла килсә әгәр,
Таянам мин якын дусларга.

*Кушымта:*
Җиде юллар чатында
Җан дуслар көтеп торсын.
Кайнар чәйләр белән сыйлап
Җырлап озатып куйсын!

Тормышыбыз кайный, юл йөреми булмый,
Мең-мең эшләр туа көн саен.
Сагынып көтә өйдә, сагынып көтә көн дә
Балаларым, газиз җанкаем.

*Кушымта.*

Такыр булсын юллар, юлдаш булсын җырлар.
Имин туып килсен һәр еллар.
Гомерлек дус булсын, юлларда очрасын
Үзеңнән дә шәб(е)рәк җан дуслар.

## ЯРАТ ГЕЛ
Рәшит Акъегет көе
(Инсаф Галимов репертуарыннан)

Яратам дип, яр итәм дип,
Йөр(е)сәләр дә бик күпләр,
Мин аларны яратмыймын
Мин бит сине яратам.

*Кушымта:*
Син генә бул сөйгән ярым,
Син генә, тик син генә.
Син дә мине өзелеп-өзелеп,
Ярат, сөй гел генә.

Җәй аенда инде үсми
Умырзая чәчәге.